**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

программа патриот воспит.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**20.03. 2019 ЕЛ** Болгар **ШӘҺӘРЕ** **№ 188**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында 2019-2020 елларда балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү" буенча муниципаль программаны раслау турында

"Татарстан Республикасында 2014-2020 елларда физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү" турында 2014 елның 07 февралендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган 73нче карарга "Татарстан Республикасында 2014-2020 елларга физик культура, спорт, туризмны һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү турындагы программага үзгәрешләр кертү турында"гы 31.12.2016 елдагы 1085нче карарына нигезләнеп чыгарылган

**К А Р А Р:**

1. "Спас муниципаль районында 2019-2020 елларда балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү" буенча муниципаль программаны (аннары Программа) 1нче кушымта нигезендә расларга.
2. «Спас муниципаль район» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы "Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында 2019-2020 елларда балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү" буенча муниципаль программаны финанслауны тәэмин итәргә тиеш.
2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.А.Афоньшинага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1637005464

# МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында 2019-2020 елларда балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү”

# ЭЧТӘЛЕК

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ


- Кереш
- Программа нигезендә хәл ителәчәк проблеманың характеристикасы
- Төп бурычлар һәм максатлар
- Программада каралган чаралар исемлеге
- Программаны тормышка ашыру механизмы
- Программаны тормышка ашыру буенча чаралар планы

Спас муниципаль районы башкарма комитеты карарына
1нче Кушымта
«____» ____________ 2019 ел. № _____

**«2019 - 2020 елларда Спас муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы**
**ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2019-2020 елларда Спас муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» (алга таба – Программа) |
| Прогамманы эшләү өчен нигезләмә | «2017 - 2020 елларда балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль «2014-2020 елларда Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру» 73нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 декабрь, 1085 нче карарына 2 нче кушымта) подпрограммасы |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Спас муниципальайоны башкарма комитеты |
| Прогамманы эшләүчеләр | Спас муниципаль районы башкарма комитетының Яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге – Программаның координаторы<br><br>«ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ;<br><br>«ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге»;<br><br>«ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтнең җирле штабы;<br><br>ТР социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль |

| | |
|---|---|
| | районы буенча территориаль социаль яклау органы |
| Программаның максаты | Патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү, яшь буында югары патриотик рух, формалашытру, яшьләр арасында патриотлык хисен ныгыту |
| Программаның бурычлары | Җирле үзидарә органннарының патриотик юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләре һәм оешмалары, мәгариф, мәдәният, яшьләлр сәясәте учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгать һәм дини оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлекне ныгыту;<br>Балаларда һәм яшьләрдә актив гражданлык позициясен, дөньяга патриотик, рухи-әхлакый һәм толерант караш, Ватанны саклау буенча конституция бурычларын үтәүгә әзерлек формалаштыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;<br>Яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча эш юнәлешләрен һәм формаларын камилләштерү һәм мәгариф учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре, хәрби-патриотик клублар, үзәкләр, иҗтимагый берләшмәләрдә патриотик тәрбия бирү сыйфатын арттыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2019 - 2020 еллар |
| Программаны финанслау чыганаклары | Чараларны башкару өчен программа нигезендә каралган акчаның күләме Спас муниципаль районы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен башкаруга, шулай ук Спас муниципаль районы бюджетына кергән бюджетара трансфертларга бәйле үзгәрергә мөмкин.<br>- 2019 ел – 645,0 мең сум.<br>-2020 ел – 645,0 мең сум. |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | - Патриотик берләшмәләр, клубларга йөрүче балалар һәм яшьләр саны арту.<br>- Патриотик юнәлештәге чараларга күбрәк балалар һәм яшьләлрне җәлеп итү.<br>- Сәламәтләндерү лагерьларында профильле хәрби-спорт патриотик сменаларның артуы.<br>- Патриотик тәрбия бирү өлкәсендә әзерлекле белгечләрнең саны артуы. Яшьләрнең рухи-әхлакый культура дәрәҗәсенең күтәрелүе.<br>- Яшьләрне армиягә хәзерләү буенча эшнең камилләшүе. |

## I. ПРОГРАММА ХӘЛ ИТӘРГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПРОБЛЕМАНЫҢ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ.

Әлеге Программа «2017 - 2020 елларда балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль «2014-2020 елларда Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру» 73нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 декабрь, 1085 нче карарына 2 нче кушымта) подпрограммасы нигезендә эшләнгән.
Әлеге Программа Спас муниципаль районының балалар һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү системасын алга таба үстерү һәм камилләштерү буенча патриотлыкны яшьләрнең актив тормыш позициясен формалаштыруның әхлакый нигезе буларак формалаштыруга юнәлдерелгән оештыру, методик һәм мәгълүмати муниципаль чаралар комплексын үз эченә ала.
Спас муниципаль районында патриотик тәрбия бирү системасының төп элементы булып ведомствоара хезмәттәшлек принципларында муниципаль районның җирле үзидарә органнарын, мәгариф учреждениеләрен, яшьләр сәясәте, мәдәният учреждениеләрен, иҗтимагый оешмаларны (берләшмәләрне), иҗат берлекләрен берләштерүче формалаштырылган инфраструктура тора.
Әлеге инфраструктурада әйдәп баручы рольне Спас муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы барлык кызыксынучы структуралар һәм ведомстволар вәкилләре кергән балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча Координация Советы алып бара, аңа районда патриотик тәрбия бирү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен районда патриотик эш өстенлекләрен формалаштыручы һәм билгели торган , патриотик юнәлештәге балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм итү һәм үстерү, яшьләрнең, гаиләнең, гражданлык җәмгыяте институтларының, бизнес институтларының, чиркәүнең үзара тәэсирлелеген арттыру өчен өстәмә формалар һәм механизмнар булдыру тәкъдим итә.
Районда патриотик эшне Спас муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе; «ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» муниципаль учреждениесе; «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы; «Форпост» хокук бозуларга каршы көрәш буенча яшьләр (мәктәп) оешмаларының Спас территориаль үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе тормышка ашыра. Яшәү урыны буенча патриотик эшне Антоновка авылында урнашкан спорт юнәлешендәге «Витязь» яшүсмерләр клубы оештыра.
2007 елда төзелгән «Кадет интернат-мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе районда яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең авангарды булып тора. патриотик юнәлештәге учреждениеләр челтәрен үстерү өлешендә «2019-2020 елларга Спас муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү» муниципаль программасын тормышка ашыру кысаларында әлеге учреждениедә патриотик юнәлештәге чаралар, спорт турнирлары һәм ярышлар оештыру һәм үткәрү, Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчыларның истәлеген мәңгеләштерү, яшүсмерләрне һәм яшьләрне Бөек Ватан сугышы елларында якташларыбыз батырлыгы турында хәтерне саклау, эзтабарлар

хәрәкәтен үстерү, яшьләрне армиядә хезмәткә әзерләү буенча эшкә җәлеп итү буенча бурычлар хәл итеүә. Бу учреждение Спас шәһәре Сугыш һәм хезмәт ветераннары советы иҗтимагый оешмасы, «Сугышчан туганлык» район иҗтимагый оешмасы, «ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе, Спас муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, "ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» муниципаль учреждениесе, Спас тармак технологияләре техникумы ДББОСЫ белән тыгыз ведомствоара хезмәттәшлек алып бара.

Патриотик тәрбия бирү һәм социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау эшендә аның актив союздашы булып 40 кешелек 4 формирование эшчәнлегенә координация һәм юнәлеш бирүче "Форпост" хокук бозуларга каршы көрәш буенча яшьләр (мәктәп) оешмаларының Спас территориаль үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе тора.

Активлыгы һәм район җитәкчелеге тарафыннан хупланган инициативасы ярдәмендә патриотик тәрбияне оештыру үз нәтиҗәләрен бирә һәм район яшьләренең күп өлешен үз эченә ала. Ел саен патриотик юнәлештәге чараларга 5380гә якын бала һәм яшьләр җәлеп ителә.

Яшьләрне патриотик тәрбияләүгә җәлеп итүдә республика һәм муниципаль конкурслар кысаларында иң яхшы проектларга грант ярдәме күрсәтү сизелерлек этәргеч булды.

Яшь буынга патриотик тәрбия бирү эшендә Спас тармак технологияләре техникумы урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе актив катнаша.

Район яшьләренә патриотик тәрбия бирүдә музейлар актив катнаша. Бүген Спас муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә туган якны өйрәнү буенча 13 музей, хәрби дан почмагы бар, аларның һәркайсында Бөек Ватан сугышы ветераннары, халкыбызның каһарманлыгы турында экспозицияләр тупланган. Музейларда ветераннар, тыл хезмәтчәннәре, концлагерь тоткыннары, Ленинград блокадасында яшәүчеләр белән очрашулар, хәрби дан көннәренә һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар уза, аларда төп катнашучылар булып укучылар, студентлар, хезмәт коллективлары булып тора.

Патриотлыкны формалаштыру системасының мөһим элементы булып яшьләр белән эшләү юнәлешләренең, рәвешләренең һәм методларының төрлелеге булып тора: хәрби-гамәли күпкөрәшләр буенча спартакиадалар һәм турнирлар үткәрү, Бөек Ватан сугышы һәм локаль сугыш ветераннары белән очрашулар, патриотик смотр-конкурслар, батырлык дәресләре, акцияләр үткәрү. Гомуми белем бирү учреждениеләре базасында эшләүче хәрби-патриотик клублар һәм берләшмәләр эше мөһим тәрбия элементы булып тора. Бу рәттә «Болгар» хәрби-патриотик эзтабарлар отряды һәм «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәте эшчәнлеге аерым урын алып тора,

Районның рухи яктан алга киткән яшь буынын тәрбияләү системасында дәүләт символларын куллану зур әһәмияткә ия. Спорт ярышларын, хәрби-патриотик чараларны үткәрү һәрвакыт дәүләт флагларын күтәрүдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимннарын башкарудан башлана. Дәүләт символикасы элементлары шулай ук чаралар үткәрү урыннарын, мәгълүмати һәм презентация материалларын бизәгәндә кулланыла.

Патриотик тәрбия бирүдә район халкының күп милләтле составы факторы һәм аның белән бәйле милли-этник мәдәниятләрнең күптөрлелеге тулырак исәпкә алына. Илебезнең күпмилләтле булуы, милли мәдәниятләрнең төрлелеге һәм аларның бер-berенә үтеп керүе җәмгыятьнең матди һәм рухи прогрессына ярдәм итүен аңлау арта.

Район яшьләренең башка раса, конфессия, милләт вәкилләренә карата толерантлык дәрәҗәсе шактый артты. Экстремистик оешмалар идеяләре район яшьләрендә хуплау тапмый.

Районда үткәрелә торган патриотик эшкә массакүләм-мәгълүмат чараларында мәгълүмати ярдәм сизелерлек активлашты: газета (басма), муниципаль берәмлекнең интернет-порталы, социаль челтәрләр, учреждениеләр һәм оешмаларның web-сайтлары төрле дәрәҗәдәге чаралар турында оператив рәвештә хәбәр итеп, аларга игътибарны җәлеп итәләр һәм мәгълүматны һәркемгә ачык итәләр.

Шуңа карамастан, Спас муниципаль районында патриотик тәрбия системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә социаль ихтыяҗ саклана, бу исә әлеге өлкәдә программаны озайтуны таләп итә.

Барыннан да элек, яшьләрдә Ватанга хезмәт итәргә әзерлекне формалаштыру җитди һәм озак вакытлы эш таләп итә. Районның белем бирү учреждениеләрендә уздырылган социологик тикшеренү күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәткә әзерлекнең югары дәрәҗәсен яшүсмерләрне патриотик тәрбияләү буенча планлы эш алып барыла торган учреждениеләр респондентлары күрсәтә. Россия Федерациясе Кораллы көчләрен реформалаштыру, социаль ташламалар, армиядә хезмәт иткән яшьләр өчен мәгариф-карьера преференцияләре турында мәгълүмат яшьләр гражданлылыгының рухи-этик аспектын формалаштыруга уңай йогынты ясый.

Белем бирү учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү, кызыксынган барлык структураларны патриотик тәрбиядә катнашуга җәлеп итү кирәклеге мөһим аспект булып тора.

Җитештерү предприятиеләре һәм оешмаларының хезмәт коллективлары, авыл яшьләре патриотик тәрбия бирү процессына җитәрлек дәрәҗәдә кертелмәгәннәр.

Патриотик юнәлештәге иҗтимагый оешмалар саны арту аларның үзара хезмәттәшлеген һәм максатчан ярдәм күрсәтүне тәэмин итүдә системалы карашны таләп итә.

Яшьләр даирәсендә тискәре тенденцияләр үсешенә каршы торуга яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә күп балалы нык гаилә, үзләренең һәм балаларының сәламәтлегенә сакчыл караш, аларның әхлакый тәрбиясе, Ватанга корбанлык, Ватанга хезмәт итәргә әзер булу, Ватанга тугрылык, намуслылык, хакимияткә хөрмәт, хәрби батырлык һәм намус, хезмәт сөючәнлек, өлкәннәргә хөрмәт, өлкәннәр һәм авырулар турында кайгырту кебек социаль кыйммәтләрне алга җибәрүче традицион диннәрне җәлеп итү ярдәм итә ала.

Дини берләшмәләр белән берлектә яшьләр өчен белем бирү, тәрбия һәм реабилитация проектлары мөмкинлекләре дә җитәрлек файдаланылмый. Массакүләм-мәгълүмат чаралары, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре мөмкинлекләре ярдәмендә гражданнарны патриотик тәрбияләүгә активрак җәлеп итү бурычы актуаль булып кала.

Яшьләрнең рухи-әхлакый үсеше физик үсеш белән дә тыгыз үрелеп бара. Илнең киләчәге - яңы һәм тәне белән камил һәм сәламәт буын. Шуңа бәйле яшьләрне спорт белән, аерым алганда, хәрби-гамәли спорт белән шөгыльләнүгә күбрәк җәлеп итәргә кирәк.

Ачык күренгәнчә, хәзерге вакытта Спас муниципаль районында патриотик тәрбия системасын үстерү комплекслы һәм системалы юлларны, ягъни әлеге проблеманы хәл итүнең программа-максатчан ысулын куллануны таләп итә.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның төп максаты булып тора: Патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү, яшь буында югары патриотик аң формалаштыру, яшьләр арасында патриотизм хисләрен ныгыту.
Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:
Җирле үзидарә органнарының патриотик юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый һәм дини оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлеген үстерү;
Балалар һәм яшьләрдә актив гражданлык позициясен, дөньяга патриотик, рухи-әхлакый һәм толерант карашын, Ватанны саклау буенча Конституция бурычларын үтәүгә әзерлеген формалаштыру буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;
Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча эш юнәлешләрен һәм формаларын камилләштерү һәм белем бирү учреждениеләрендә, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, хәрби-патриотик клубларда, үзәкләрдә, иҗтимагый берләшмәләрдә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Патриотик тәрбия системасын модернизацияләү. Патриотик тәрбия процессын камилләштерү буенча чаралар системасында күздә тотыла:
- хәзерге этапта патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;
- патриотик тәрбия эчтәлеген баету;
- патриотик тәрбия бирүнең инновацион формаларын һәм алымнарын үстерү;
- эзләнү эше һәм Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү;
- "ЮНАРМИЯ" хәрби-патриотик хәрәкәтендә катнашучылар санын сизелерлек дәрәҗәдә арттыру,
- җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә, Ватанны саклау буенча бурычларны үтәүгә әзерлек тәрбияләү;
- Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре белән патриотик тәрбия өлкәсендә хезмәттәшлекне тәэмин итү;
- патриотик тәрбия процессы белән идарә итү системасын камилләштерү;
- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү;
- патриотик тәрбия бирү системасында бара торган процессларны норматив-хокукый көйләү юлы белән патриотик тәрбия бирү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру.

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар системасы берничә максатны күздә тота:
- хәрби хезмәтнең абруен күтәрү;
- яшьләрне сәламәтләндерү, физик һәм психологик яктан әзерләү;
- спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен популярлаштыру;
- хәрби хезмәткә чакырылучыларның белем дәрәҗәсен күтәрү, алар тарафыннан хәрби-учет белгечлекләре алу;
- гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.

Патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин ителеш.

Патриотик тәрбиянең мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик нигезләрен үстерү буенча чаралар системасы күздә тотыла:
- Спас муниципаль районында балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү формаларын, методларын һәм чараларын эшләү;
- патриотик эш практикасына кертү максатында патриотик тәрбия бирү өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү;
- район халкының патриотик аңын формалаштыруга иҗтимагый-тәрбияви йогынты ясауның актив формаларын үстерү;
- массакүләм мәгълүмат чаралары өчен патриотлыкны пропагандалауда тулырак катнашу өчен шартлар тудыру;
- телевидение программаларында, вакытлы матбугатта патриотик тематикага ярдәм итү;
Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар планы аңа Кушымтада китерелгән.

## IV. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ.

Программаның төп башкаручылары булып тора: Спас муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, "Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль учреждениесе, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» муниципаль учреждениесе, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, шулай ук чаралар үткәрүне гамәлгә ашыручы оешмалар.
Программаны гамәлгә ашыру кысаларында башкаручылар тарафыннан түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыру күздә тотыла:
алар тарафыннан патриотик тәрбия бирү программаларын (планнарын) эшләү һәм аларны гамәлгә ашыруны оештыру (һәр чара буенча башкарырга кирәкле эшләрне, чыгымнарны һәм аларны финанслау чыганакларын күрсәтеп).

«2019-2020 елларда Спас муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» Спас муниципаль районы башкарма комитеты программасына
2нче Кушымта

# «2019-2020 елларда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» Муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чаралар планы

| № | Чараларның эчтәлеге | Башкару срогы | Финанслау (мең сум) | | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2019 | 2020 | |
| **I. Патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү** | | | | | |
| 1. | Яшәү урыны буенча хәрби-патриотик, спорт һәм туган якны өйрәнү юнәлешендәге клублар берләшмәләренең материаль-техник базасын ныгыту, челтәрен киңәйтү (ФОРПОСТ штабы, ЮНАРМИЯ штабы) | 2019-2020 | 100,0 | 100,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 2. | Төрле типтагы балалар савыктыру лагерьларындагы профильле сменаларда патриотик һәм спорт юнәлешендәге чаралар оештырып үткәрү | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | "ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге" МУ, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 3. | Мәгариф учреждениеләрендә гражданлыкны үстерү һәм хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча иң яхшы программага конкурс турында положениене эшләү һәм оештыру | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 4. | Музейлар, заллар, район мәгариф учреждениеләрендәге хәрби дан почмакларында экспозицияләрне киңәйтү | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтнең җирле штабы, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы, ТР Спас муниципаль районы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 5. | Яңа оештырылган «ЮНАРМИЯ» отрядлары өчен форма сатып алу | 2019-2020 | 40,0 | 40,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 6. | «Аҗаган», «Орлёнок» Бөтенроссия хәрби спорт уенының район этабын оештырып үткәрү | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 7. | Тарихи һәм истәлекле урыннар буенча туган якны өйрәнү буенча туристик походлар үткәрү | Ел әйләнәсендә | 3,0 | 3,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 8. | Әһәмиятле тарихи даталарга багышланган патриотик темалар буенча иҗади эшләрнең Бөтенроссия юнармиячеләр конкурсларының район этапларын үткәрү. Хәрби дан көннәренә һәм Россиянең истәлекле даталарына багышланган чаралар кысасында. | Ел әйләнәсендә | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 9. | «Легендадан кешеләр» иҗади проектлар конкурсы. «Безнең як һәм аның кешеләре сугыш елларында» темасына укучыларның туган якны өйрәнү проект-тикшерүләре күргәзмәсе. | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 10. | Спас муниципаль районында иң яхшы кадет классына (төркеме) конкурс | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 11. | Спортның хәрби-гамәли һәм техник төрләре буенча «Ватанның тугры уллары» ярышларында катнашу | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 12. | «Иң яхшы юнармиячеләр отряды» конкурсын үткәрү.<br>Иң яхшы отрядларны сайлап алып (номинацияләр буенча), яңа ел бәйрәм чаралары кысаларында бүләкләү тантанасын уздыру | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы; |
| 13. | «Иминлек мәктәбе» республика ярышларында катнашу | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 14. | Юнармиячеләр отрядларының хәрби-тарихи һәм туган якны өйрәнү музейларына, хәрби частьләрнең хәрби дан музейларына экскурсияләрен оештыру | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы; |
| 15. | Гомумбелем бирү мәктәпләрендә укучылар өчен “Тарихи шимбә” Россия хәрби-тарихи җәмгыяте лекторийларын уздыру. Юнармиячеләрнең Россия тарихына багышланган лекторийларда катнашуы. «Юнармия» һәм Россия хәрби-тарихи җәмгыятенең региональ бүлекләре аша “Тарихи шимбәләр” үткәрү тәҗрибәсен тарату | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 16. | «Минем кече Ватаныс», «Туган як серләре» республика конкурсларында катнашу. | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 17. | «Тормыш иминлеге нигезләре» дисциплинасы буенча иң яхшы укытучы» конкурсын уздыру | Аерым план буенча | 3,0 | 3,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 18. | Батырлык дәресләре, Россиянең истәлекле даталары һәм хәрби дан көннәренә багышланган класс сәгатьләре, әдәби кичәләр, класстан тыш чаралар уздыру | 2019-2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 19. | Бөтенроссия «Президент бәйгесе», «Президент уеннары» укучылар спорт-савыктыру уеннарының республика этабында катнашу. | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 20. | «Горурланабыз синең белән, Ватан!» хәрби-патриотик җыры район фестивален оештырып үткәрү | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ; |
| 21. | «Гражданлык һәм партиотлык сәгате» яшьләлр акциясен уздыру | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | Балалар иҗат йорты |
| 22. | «Мин – Россия гражданины» паспортлар тапшыру буенча яшьләлр патриотик акциясе | Квартал саен 2019-2020 | 8,0 | 8,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Федераль миграция хезмәте идарәсенең Спас муниципаль районы бүлеге; |
| 23. | Патриотик тәрбия бирүгә предприятие, оешма коллективларын, яшьләр | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | берләшмәләрен җәлеп итү. | | | | |
| 24. | Мәгариф учреждениесендә укучылар белән Ватан сакчылары һәйкәлләре, Бөек Ватан сугышында һәм локаль бәрелешләрдә катнашучылар каберләрен тәртипкә китерү буенча акцияләр уздыру | 2019-2020 | - | - | Авыл җирлекләре, патриотик клублар һәм берләшмәләр, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ; |
| 25. | Уку йортларында, яшүсмер клубларында балаларның һәм яшьләрнең сугыш, хезмәт ветераннары, хәрби бәрелешләрдә катнашучылар белән очрашуларын оештыру | даими | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ |
| 26. | Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары, локаль бәрелешләрдә катнашучылар исемлеген даими яңартып тору | даими | - | - | ТР Социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районы буенча территориаль бүлеге |
| 27. | Ветераннарга һәм тыл хезмәтчәннәренә, хезмәт ветераннарына һәм хәрби бәрелешләрдә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча эшне оештыру | даими | - | - | ТР Социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районы буенча территориаль бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, волонтерлар |
| 28. | Һәр торак пункты буенча сугыш елларында һәлак булучылар һәм хәбәрсез югалучылар турында "Бөек Ватан сугышы мемориалы" сайты картотекасыннан файдаланып электрон вариантта Хәтер китабын ясауга район гомумбелем мәктәпләре укучыларын җәлеп итеп семинар-тренинг уздыру | 2019-2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтнең җирле штабы |
| 29. | Идел буе федераль округының эзтабарлар слетында катнашу | 2019-2020 | 10,0 | 10,0 | Эзтабарлар отряды, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 30. | Россия Оборона министрлыгы, Россия хәрби-тарихи берләшмәсе | 2019-2020 | 150,0 | 150,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | һәм Рус география җәмгыяте планнары буенча эзтабарлар экспедицияләрендә катнашу: «Невский пятачок»; «Волховский фронт-3»; «Фронт»; «Западный фронт-4»; «Аджимушкайские каменоломни». Һәлак булган сугышчыларның җәсәдләрен күмү буенча тантаналы матәмнәрдә катнашу | | | | комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 31. | Һәлак булган диңгезчеләргә хөрмәт күрсәтү максатыннан елгага веноклар кую буенча мемориаль чараларда катнашу | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 32. | 1918-1921 еллардагы Гражданнар сугышының Спас районы территориясендә булган бәрелешләр буенча эзтабар экспедицияләрендә катнашу | 2019-2020 | 30,0 | 30,0 | «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 33. | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмасының эшен оештыру «Байкерлар һәм туган як тарихы» слетын оештырып үткәрү | даими июль 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «Форпост» үзәге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 34. | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган чараларны үткәрү | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ |
| 35. | Ватан саклаучысы көненә багышланган оборона-массакүләм эш айлыгын уздыру | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, «Форпост» үзәге |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 36. | Укучылар арасында Татарстан Республикасы дәүләт символикасын иң яхшы белүчегә район конкурсын уздыру һәм республика конкурсында катнашу | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «Форпост» үзәге |
| 37. | Җиңү көненә, Россия Хәрби даны көннәренә һәм истәлекле көннәргә (ТАССРга 100 ел тулу) багышланган бәйрәм чараларын оештыру) | 2019-2020 | 30,0 | 30,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, ТР Социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районы буенча территориаль бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, кызыксынган затлар |
| 38. | ТАССРның 100 еллыгына багышланган бәйрәм чараларына хәзерләнү һәм оештырып үткәрү (баннерлар, логотиплар ясау һәм башкалар) | 2019-2020 | 30,0 | 30,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ, ТР Социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районы буенча территориаль бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, кызыксынган затлар |
| **II. Яшь гражданнарның чакырылыш алды хәзерлеге буенча чаралар.** | | | | | |
| 39. | Яшьләрне хәрби хезмәткә хәзерләү мәсьәләләре буенча дәүләт (муниципаль) органнары һәм | даими | - | - | «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | башка оешма җитәкчеләре белән өйрәтү-методик киңәшмәләр һәм конференцияләр үткәрү | | | | штабы, башкарма комитет |
| 40. | Уку йортларының материаль-техник гамәли һәм спорт базасын ныгыту буенча эшчәнлек | 2019-2020 | 20,0 | 20,0 | Башкарма комитет, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ |
| 41. | Районда Призывник көнен оештырып үткәрү | Яз, көз 2019-2020 | 30,0 | 30,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 42. | Тормыш иминлеге нигезләре курсы буенча өлкән класс укучылары арасында кыр җыеннарын оештырып үткәрү. | 2019-2020 | 40,0 | 40,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 43. | Хәрби хезмәткә чакырылыш барганда, яшьләр белән чаралар циклын (ветераннар белән очрашулар, ачык ишекләр көне һәм башкалар) уздыру | 2019-2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, ТР Социаль яклау министрлыгының Спас районы буенча территориаль бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 44. | Район юнармиячеләренең Россия Федерациясе субъектларының һәм Россия ДОСААФының җәйге оборона-спорт сәламәтләндерү лагерьларында катнашуы һәм түбәндәгеләргә өйрәнүе:<br>урынны билгеләү;<br>палатка кую; | 2019-2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | учак тергезү;<br>зыян күрүчеләргә беренче ярдәмне күрсәтү | | | | бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 45. | «Вертолетный» утравында ТР эзтабарларының кырда өйрәтү җыенын үткәрүне оештыруда ярдәм күрсәтү | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 46. | П.А. Карпов исемендәге кадет интернат-мәктәбендә “Кадет анты” хәрби антны кабул итү тантанасын үткәрүне гамәлгә кертү, бу тантаналарга чакырылыш алды яшендәге егетләрне, ата-аналарны, ветераннарны чакыру | 2019-2020 | - | - | «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ, кадет мәктәп-интернаты ДБУ |
| 47. | Спас муниципаль районы егетләре армия хезмәтен үтә торган хәрби частьләргә район делегацияләрен җибәрү | 2019-2020 | 30,0 | 30,0 | Спас муниципаль районы башкарма комитеты, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге» МУ |
| 48. | Район җыелма командаларының «Аҗаган» һәм «Орленок» республика зональ хәрби-спорт уеннарында катнашуы | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ |
| 49. | Рус армиясенең тарихи әһәмияткә булган җиңүләренә, Бөек Ватан сугышында совет гаскәрләренең җиңүләренә, Җиңү бәйрәменә багышланган ату буенча спорт ярышларын үткәрү | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 50. | Өч яшь категориясендә (Кадетлар. Юниорлар. Призывниклар) спортның хәрби-гамәли төрләре буенча район спартакиадаларын үткәреп, җиңүчеләрдән зона һәм республика ярышларында катнашу өчен җыелма командалар оештыру. | 2019-2020 | 3,0 | 3,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы. |
| 51. | Район командаларының спортның хәрби-гамәли төрләре буенча республика ярышларында катнашуы. | 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «Форпост» үзәге |
| 52. | Хәрби частьләлр белән шефлык элемтәләлрен ныгыту | 2019-2020 | - | - | Башкарма комитет, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 53. | Спас районы егетләре хезмәт итә торган хәрби частьләр белән хатлар язышу. Спас районыннан хезмәт итүчеләр өчен посылкалар, открыткалары җыеп җибәрү, аларга мораль ярдәм күрсәтү, хәрби частьләрдән бәяләмәләр соратып алу. | даими | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 54. | Хәрби хезмәттә булучыларның ата-аналары белән очрашу. | даими | - | - | Спас муниципаль районы башкарма комитеты, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 55. | Гомумбелем бирү учреждениеләре арасында Ватан саклаучысы көненә багышланган саф белән йөрү һәм җыр район конкурсын оештырып үткәрү | Февраль 2019-2020 | 5,0 | 5,0 | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «Форпост» |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | үзәге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 56. | Призывниклар арасында үткәрелә торган «Яшьләрне хәрби хезмәткә хәзерләү» ярышларында катнашу | 2019-2020 | 7,0 | 7,0 | «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «Форпост» үзәге |
| **III. Патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин итү.** | | | | | |
| 57. | Мәгариф учреждениеләрендә кертү өчен балаларга һәм яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүдә эш тәҗрибәсен яхшырту буенча фәнни-теоретик һәм практик тәҗрибәне исәпкә алган методик кулланма эшләү | 2019 - 2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ЮНАРМИЯ» хәрби-патриотик хәрәкәтенең җирле штабы |
| 58. | Мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирүне оештыручыларның, патриотик берләшмә җитәкчеләренең квалификацияне күтәрү курсларында катнашуын оештыру. | 2019-2020 | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ |
| 59. | Массакүләм-мәгълүмат чараларында патриотик тәрбия бирүне иң яхшы яктырту буенча “Россия патриоты” Бөтенроссия конкурсында катнашу | 2019-2020 | - | - | «Новая жизнь-Яңа Тормыш» район газетасы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ |
| 60. | Спас муниципаль районы рәсми сайтында “Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү” бүлеген булдыру һәм аны даими яңарту | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге |
| 61. | Китапханәләрне патриотик һәм туган якны өйрәнү юнәлешендәге | даими | - | - | «ТР Спас муниципаль районы башкарма |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ |
| 68. | Яшьләр берләшмәләре, патриотик клублар һәм берләшмәләр җитәкчеләре белән “Яшьләрнең Россиядә гражданлык җәмгыятен формалаштыруда катнашуы” темасына “түгәрәк өстәл” утырышларын үткәрү | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, яшьләр берләшмәләренең лидерлары |
| 69. | Спорт һәм патриотик юнәлештәге профильле палаткалы лагерьлар өчен педагог-тәрбиячеләр әзерләү буенча семинарлар үткәрү | 2019-2020 | - | - | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, «ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ |
| 70. | «Новая жизнь – Яңа Тормыш» газетасы битләрендә хәрби-патриотик клублар, берләшмәләр, түгәрәкләр эшчәнлеген яктыртучы рубрикалар булдыру | даими | - | - | «Новая жизнь-Яңа Тормыш» район газетасы |
| 71. | Россия, Татарстан Республикасының патриотик, тарихи һәм заманча символикасын чагылдырган күргәзмә әсбаплар, плакатлар, сувенир продукциясен ясау һәм чыгару | 2019-2020 | 15,0 | 15,0 | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, кызыксынган затлар белән берлектә |
| **Барлыгы:** | | | 645,0 | 645,0 | |